| | | |
|---|---|---|
| ГЛАВА МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ «ЛЕНИНОГОРСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН», МЭР ГОРОДА ЛЕНИНОГОРСКА | | «ЛЕНИНОГОРСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ» МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ БАШЛЫГЫ ЛЕНИНОГОРСК ШӘҺӘРЕ МЭРЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

28.04.2026 г.Лениногорск № 32

«Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башлыгы, Лениногорск шәһәре мэрының «Муниципаль заказга кертелмәгән Лениногорск шәһәре һәм Лениногорск районы даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу маршруты буенча пассажирлар йөртү һәм багаж ташу хокукына конкурс үткәрү тәртибе турында» 2016 елның 29 июлендәге 101 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2025 елның 31 июлендәге 304-ФЗ номерлы (28.12.2025 ел редакциясе) Федераль закон нигезендә КАРАР БИРӘМ:

«Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башлыгы, Лениногорск шәһәре мэрының «Муниципаль заказга кертелмәгән Лениногорск шәһәре һәм Лениногорск районы даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу маршруты буенча пассажирлар йөртү һәм багаж ташу хокукына конкурс үткәрү тәртибе турында»2016 елның 29 июлендәге 101 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

преамбулада «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон белән» сүзләрен «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 25 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль закон белән» сүзләренә алмаштырырга;

муниципаль заказга кертелмәгән Лениногорск шәһәре һәм Лениногорск районы даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу маршруты буенча пассажирлар йөртү һәм багаж ташу хокукына конкурс үткәрү тәртибе турындагы Нигезләмәдә:

1.3 пунктны түбәндәге эчтәлекле 5 пунктча белән тулыландырырга:

«5) даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу маршруты картасы - даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның халыкара

маршрутларыннан тыш, әлеге маршрут буенча файдаланырга рөхсәт ителә торган даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу маршруты һәм транспорт чарасы турында белешмәләр булган электрон документ»;

2.2.2 пунктта:

2 пунктчада «әлеге таныклыкның гамәлдә булу хокукы» сүзләрен «даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу маршруты буенча пассажирлар йөртү һәм багаж ташу хокукы»сүзләренә алмаштырырга;

3 пунктчада «бирелгән таныклык» сүзләрен «даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу маршруты буенча пассажирлар йөртү һәм багаж ташу хокукы бирелде» сүзләренә алмаштырырга;

2.2.3 пунктта:

1 абзацта «гамәлгә ашыру турында таныклык» сүзләрен «гамәлгә ашыру хокукы»сүзләренә алмаштырырга;

2 нче абзацта «эшчәнлекне үтәү турында таныклыклар» сүзләрен «эшчәнлек үтәү хокуклары» сүзләре белән алыштырырга;

2.5 пунктта «Эшчәнлекне үтәү турында таныклыкны алу өчен» сүзләрен «Эшчәнлек үтәү хокукы» сүзләренә алыштырырга;

4.1 пункт 2 нче абзацында «эшчәнлекне үтәү турында таныклык бирелә» сүзләрен «эшчәнлек үтәү хокукы бирелә» сүзләре белән алыштырырга;

6.2 пункт 9 нчы абзацында «эшчәнлекне үтәү турында таныклык бирә» сүзләрен «эшчәнлек үтәү хокукын тәэмин итә» сүзләре белән алыштырырга;

8.16 пунктында:

2 пунктчада «йә даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу маршруты буенча пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыру турында таныклыклар» сүзләрен төшереп калдырырга;

4 нче пункт астында «эшчәнлекне үтәү турында таныклыклар» сүзләрен «эшчәнлек үтәү хокуклары» сүзләре белән алыштырырга;

карарга 1 нче кушымтаның 2.3.4 пунктында «Казан» сүзен «Лениногорск» сүзе белән алыштырырга;

4 нче кушымтаны төшереп калдырырга.

3. Әлеге карарның 2 нче пункты 2026 елның 1 сентябреннән үз көченә керә.

4.Әлеге карарны рәсми публикатор - «Лениногорские вести» газетасында бастырырга, Лениногорск муниципаль районының рәсми интернет-сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

5.Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Лениногорск шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты җитәкчесенә йөкләргә.

М.Н. Гирфанов

Хәйбрахманов И.Р.
5-44-72